Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы

КАРАР № 16

Кәрәкәшле авылы «15» июнь 2015 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшлеавыл җирлеге Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешүне раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 124, 125 һәм 421 статьялары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшлеавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча Кәрәкәшле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда үзара эшчәнлеге турындагы Килешүне расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының «Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында» гы 2015 елның 25 нче февралендәге 3 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан стендларда һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында: http://jutaza.tatarstan.ru. урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А. Г. Дәүләтгәрәев

Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы
2015 елның 15 нче июнендэге
16 санлы карарына
Кушымта

| | |
|---|---|
| Ютазы муниципаль район Советы Карары белән Расланды | Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы Карары белән Расланды |
| «___» _____________2015ел | «___» _____________2015 ел |

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда идарә итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеге турында Килешү**

Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты, алга таба «җирлек башкарма комитеты» дип атала, бер яктан, Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы Устав нигезендә эш итүче Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улы, һәм Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты, алга таба «район Башкарма комитеты» дип атала, Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе Устав нигезендә эш итүче Подовалов Андрей Николаевич, икенче яктан, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 124, 125 һәм 421 статьялары нигезендә түбәндәгеләр турында Килешү төзеделәр.

**1. Килешү предметы һәм принциплары**

1.1. Әлеге килешү җирлек Башкарма комитетының һәм район Башкарма комитетының дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр (авыл) җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча Кәрәкәшле авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булганда (алга таба – җир кишәрлекләре) үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Килешү түбәндәге принципларга нигезләнгән:

а) җирлек халкының мәнфәгатьләрен тәэмин итү, халыкка җирле үзидарәгә хокукны гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү;

б) җирлек территориясендә җирле үзидарәне нәтиҗәле үстерүгә ярдәм итү;

в) җирле үзидарәне торгызу һәм үстерү өчен кирәкле хокукый, оештыру шартлары тудыру;

г) җир кишәрлекләре белән эш итү буенча карарлар кабул итү буенча үз вәкаләтләрен җирлек башкарма комитеты тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашыру;

д) җир сәясәтенең бердәмлеге;

е) документларны гамәлдәге законнар нормаларын исәпкә алып, сыйфатлы итеп рәсмиләштерү.

**2.** Якларның бурычлары

2.1. Район Башкарма комитетының бурычлары:

2.1.1. җирлек башкарма комитетына җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләрендә, шул исәптән:

а) физик һәм юридик затлардан документлар кабул итүне оештыру;

б) җир кишәрлекләре белән муниципаль район органнары һәм учреждениеләре, шулай ук дәүләт хакимияте органнары белән эш итү мәсьәләләре буенча җирлек Башкарма комитетының әзерләнә торган карарлары һәм документлары проектларын килештерү кирәк булган очракта Оештыру;

в) җир кишәрлекләре белән эш итү мәсьәләләре буенча җирлек башкарма комитеты карарлары проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү, шул исәптән: җир кишәрлеген бирүне (законда билгеләнгән очракларда), милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга алдан килештерү, җир кишәрлекләреннән сервитут бирмичә һәм билгеләмичә файдалануга рөхсәтләр бирү, түләүсез файдалану һәм чикләнгән файдалануның теләсә нинди төрләрен билгеләү турында (сервитутлар) яисә җирләрдән файдалану буенча башка чикләүләр;

г) аренда, сату-алу, түләүсез файдалану, чикләнгән файдалану (сервитут)шартнамәләре проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

д) җир кишәрлеген алмаштырганда карарлар проектларын (шулай ук алмашу шартнамәсе проектын) әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

е) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту хакындагы карарлар төзүгә ризалык проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

ж) законнарда билгеләнгән очракларда җир кишәрлегенең урнашу схемасын, шулай ук аны раслау буенча җирле үзидарә органы карары проектын әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

з) җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен билгеләү, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында җирлек башкарма комитеты карарлары проектларын әзерләүдә ярдәм күрсәтү.

и) карарлар, башка документлар проектларын әзерләүдә һәм җир кишәрлекләрен сату буенча торглар, шулай ук аренда шартнамәләре һәм җир кишәрлекләренә карата хокукларның күчүен күздә тота торган башка шартнамәләр төзү хокукына торглар оештыруда ярдәм күрсәтү;

к) төзелгән шартнамәләр чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен түләүләрне тикшереп тору һәм бурычны түләү турында дәгъвалар әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

л) җир кишәрлекләре белән эш итүгә бәйле салым булмаган керемнәрнең аерым төрләренең тулылыгын һәм үз вакытында керүен исәпкә алу һәм тикшереп тору, әлеге керемнәрне администрирование итү һәм Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләре белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

м) Дәүләт статистикасы органнарына федераль статистик күзәтү рәвешләре буенча хисаплылык тапшыруны тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;

н) әлеге килешүдә билгеләнгән мәсьәләләр буенча оешмаларда, кредиторлар җыелышларында, гомуми юрисдикция судларында, арбитраж судларында җирлек башкарма комитеты мәнфәгатьләрен ышанычнамә нигезендә яклау;

о) әлеге килешүдә билгеләнгән мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекләр арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру;

п) дәүләт теркәве органнарында җир кишәрлекләренә хокукның һәм милек хокукының күчүен һәм алыш-бирешләрне ышанычнамә нигезендә теркәү;

р) җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны төгәлләштерелә торган тиешле кадастр эшләре башкарылган очракта җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынын килештерү буенча бәяләмәләр әзерләүдә ярдәм күрсәтү;

с) җиргә дәүләт милке чикләнгәндә авыл җирлекләренең җир кишәрлекләренә хокукын дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү;

2.1.2. 2.1.1 п.күрсәтелгән гамәлләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тәэмин итү. әлеге килешүнең;

2.1.3. җирлек башкарма комитеты соравы буенча җир кишәрлекләренә карата кирәкле мәгълүмат бирү;

2.1.4. җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча җирлек башкарма комитетына консультатив-хокукый ярдәм күрсәтү;

2.2. Җирлек Башкарма комитетының бурычлары:

2.2.1. район Башкарма комитеты гарызнамәсе буенча җирлек башкарма комитеты карарлары проектларын, шартнамәләр һәм килешүләр әзерләү өчен кирәкле документларны тапшыру;

2.2.2. район башкарма комитетына, кирәк булган очракта, шушы Килешү вәкаләтләре чикләрендә җирлек башкарма комитеты исеменнән гамәлләрне башкаруга ышанычнамә бирү;

2.2.3. район башкарма комитетына булган җир-кадастр, җир төзелеше һәм шәһәр төзелеше документларын, башка документларны бирү һәм район Башкарма комитеты тарафыннан җир кишәрлекләре белән идарә итү документлары проектларын әзерләүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкару өчен кирәкле булган мәгълүматны бирү;

2.2.4. мәгълүмати-белешмә хезмәте күрсәтү белән тәэмин итү;

2.2.5. җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча әзерләнгән карарлар проектларына үз вакытында кул кую һәм аларны теркәү.

**3.** Килешүнең гамәлдә булу вакыты һәм гамәлдә булмау тәртибе

3.1. Әлеге килешү Ютазы муниципаль районының вәкиллекле органы һәм Кәрәкәшлеавыл җирлегенең вәкиллекле органы тарафыннан расланган көннән үз көченә керә һәм өч ел дәвамында гамәлдә була.;

3.2. Әлеге килешү якларның килешүе буенча вакытыннан алда туктатыла. 3.3. Килешү өзелү язма рәвештә рәсмиләштерелә.

3.4. Әлеге килешүне вакытыннан алда өзү турында Карар кабул иткән як икенче якка фаразланган өзү көненә 30 көн кала хәбәрнамә һәм өзү турында килешү проектын җибәрә. Хәбәрнамә һәм өзү турында килешү проектын алган як өзү турында имзаланган килешүне яисә дәлилләнгән баш тартуны алган көннән алып 10 көн эчендә җибәрергә тиеш.

3.5. Әгәр әлеге килешүнең гамәлдә булу вакыты тәмамланырга бер ай кала якларның берсе дә аны туктату турында белдермәсә, килешү шул ук вакытка һәм шул ук шартларда озайтылган дип санала.

**4.** Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы булалар.

**5.** Йомгаклау шартлары

5.1. Якларның үзара ризалыгы буенча яисә гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә әлеге килешүгә язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яисә) өстәмәләр кертелергә мөмкин. Әлеге килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр якларның өстәмә килешүе белән рәсмиләштерелә.

5.2. Әлеге Килешү бертигез юридик көчкә ия якларның һәркайсы өчен 2 (ике) нөсхәдә, берәр нөсхәдә төзелде.

5.3. Әлеге Килешүне үтәгәндә яклар арасында барлыкка килә торган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар сөйләшүләр юлы белән хәл ителәчәк.

5.4. Әлеге килешү белән, шул исәптән финанс белән тәэмин итү белән җайга салынмаган мәсьәләләр муниципаль берәмлекләрнең аерым актлары, гамәлдәге законнар нигезендә кабул ителгән килешүләр белән җайга салына.

**6.** Якларның адреслары һәм башка белешмәләр

| «Авыл җирлеге башкарма комитеты» | «Район башкарма комитеты» |
| --- | --- |
| Кәрәкәшле авыл җирлеге Башкарма комитеты | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Урнашу урыны: 423961, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Каракашлы ав., Мирфатыйх Зәкиев ур., 47 й. | Урнашу урыны: 423950, Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Урыссу ш. т. п., Пушкин ур., 38 й. |
| ИНН ____ | ИНН _________ |
| Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы | Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесе |
| _______________ А. Г. Дәүләтгәрәев | _______________ А.Н.Подовалов |
| МП | МП |